| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» 05 2025 ел № 125

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Смәил авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район башлыгы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Смәил авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча Смәил авыл җирлеге халкы катнашында гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы И.Н.Сәгъдиев;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И. М. Фәтхетдинов;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты юридик бүлеге мөдире Р.С.Фатыхов;
- ГБУ "ФПД РТ" вәкиле.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар уздыру белән кызыксынучы затларга хәбәр итү вакытыннан башлап гавами тыңлауларның йомгаклары турында нәтиҗәләр басылып чыккан көнгә кадәр бер айдан артык вакыт узарга тиеш түгел.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр әзерләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль район
башлыгы

Р. Р. Нотфуллин